**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**Сарманавылжирлеге**
**423350 Сарманавылы,**
**М.Жэлилур., 63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E - mail: Sar.sar @ tatar.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

**Сармановское сельское**
**поселение**
**САРМАНОВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
**423350 с. Сарманово,**
**ул.М.Джалиля, 63**
**тел.: 2-43-67, 2-45-38**
**E – mail: Sar.sar @ tatar.ru**
ИНН/КПП 1636001266/163601001

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06 апреля 2023 г. № 3

Хайваннарны хуҗалардан башка кире кайтару тыела торган урыннарны билгеләү турында һәм хайваннарны хуҗаларыннан башка элеккеге яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм хайваннарга карата җаваплылык турында» 2022 елның 14 июлендәге 269-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә хайваннарны хуҗалардан башка кайтару тыела торган түбәндәге урыннарны билгеләргә:
ФАП территориясе;
мәктәп территориясе;
балалар бакчасы территориясе;
парклар, скверлар территориясе;
балалар уен мәйданчыклары территориясе.

2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Сарман авыл җирлеге» башкарма комитеты җитәкчесе Шәрипова Лилия Иван кызын - хуҗалардан башка терлекләрне элекке яшәү урыннарына кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле зат итеп билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Сарман районы: Сарман авылы, Ленин урамы, 38, Ленина урамы, 1А һәм Сарман муниципаль районының рәсми интернет-сайтының (https://sarmanovo.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Азалак авыл җирлеге башлыгы Ф.М.Хөснуллин